

УЗЕҢ БЕЛӘСЕҢ
Белгечләр коронавирусны ачыклаучы экспресс-тест нәтиҗәләренә ышанып бетмәскә киңәш итә
> 2

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК
«ВТ» укучыларының күңелендә саклаган хатирә-истәлекләре
> 3

БАЛА ХӘСРӘТЕ
Яшьлегендә күпне кичергән Гөлниса әбигә олыгайган көнендә дә тынычлык язмаган
> 4

АЛТЫН БӨРТЕГЕ
Камилә Вәлиева команда ярышларында Олимпия чемпионы булып танылды
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 18 (28791) | Сишәмбе | 8 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ҺӘР КӘГАЗЬ ДӘ ТҮЛӘҮ ӨЧЕН ТҮГЕЛ

ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘ МОШЕННИКЛАР ҖИТӘРЛЕК

Тикшертмәсәң, күбрәк түләрсең. Соңгы арада Казан халкы торак-коммуналь хуҗалык оешмаларыннан чираттагы «сәлам хатлары»на юлыга башлады. Кәгазьдә сүз суны исәпкә ала торган җиһазлар турында бара. Имеш, аларны куллану вакыты чыкмаганмы, тикшертергә кирәк, югыйсә су өчен арттырып түлисе. Кесәдән артык тиен чыгармыйсы иде дә бит, әмма тиз ышанучан кешеләргә соңрак кыен ашарга туры килмәгәе. Бигрәк тә хатта акка кара белән күңелгә шом кертерлек сүзләр һәм саннар язылса...

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хат эчтәлеге

Хөкүмәт карары нигезендә фәлән елның фәлән аеннан суны исәпкә ала торган җиһазларны карату яңадан башланган икән (сорау: кайчан туктатылган иде икән соң ул?). Җиһазның төзеклеген исә «Центр Метрологии ЖКХ» тикшерә. Белгеч килә, счетчик яраклымы-юкмы, алга таба кулланырга ярыймы-юкмы – барысын да караячак, ди. Алмаштырсын дисәгез, шалтыратып, чиратка языласы. Шунда ук телефон номеры да бар. Фәлән айның фәлән көненә кадәр белгеч чакыртмасаң, су өчен күбрәк түләячәгеңне искәртәләр. Барлык нормативлар белән таблицасы да янәшәдә генә урын алган.

Белдерү кәгазенә бәйләнерлек нигез юк кебек. Әйтик, номерлары да, кайсы адрестан, оешмадан җибәрелгәне дә, мөһере дә, имза дигәннәре дә бар. Закон сүзе дә берничә җирдә очрый. Сүзе булгач, үтәргә кирәк, димәк! Хәтта замананың аерылгысыз бер өлешенә әверелгән QR-код та сырланган, шулай булгач, ышанмый кара!

Бары да бар, әмма хатның кемгә атап язылганы, ягъни фатир хуҗасы, фатир, счет номерлары гына күрсәтелмәгән. Димәк, әллә бу хат сиңа, әллә күршеңә – кем белсен? Чагыштыра торгач, шунысына да игътибар итәсең: кәгазьгә имза куючының да, оешмасы бер булса да, җитәкчеләренең фамилияләре төрле. Әйтик, берәүләр өчен Авакумов, икенчеләр өчен Полетаев йә Правда дигән кеше, борчылып, хатлар юллый икән.

Тикшерергә иренмә икән

– Почтадагы кәгазьләргә артык игътибар биреп тормыйсың инде ул. Кем нәрсә тәкъдим итмәс?! Гадәттә, миңа гел суши, пицца рекламалары чыга. Бу «сәлам хаты»на игътибар итәргә туры килде инде. Сүз бит акча, коммуналь хезмәтләр өчен түләү турында бара, – ди Фатих Әмирхан урамындагы йортларның берсендә яшәүче Рәйдә Нигъмәтҗанова. – Дөресен әйткәндә, бу кәгазьләр җәйдән бирле килә инде. Айлары гына үзгәреп тора, таләпләре – шул ук. Башта шунысы гаҗәпләндерде. Әйтик, июньнән бирле килә торган кәгазьгә ышансаң, мин һәр ай арттырып түлим булып чыгамы? Алайса, таләпләрне үтәмәгән өчен суны ник өзмәделәр икән? Чын счет-фактура кәгазендә исә түләүгә бәйле әллә ни үзгәреш сизмәдем. Фатирда бүлмә «снимать» итеп яшим. Кәгазьне хуҗасына күрсәттем. Ул исә җиһазларның тәртиптә булуын, әле былтыр гына яңага алмаштырганын әйтте.

Профессор Камай урамында яшәүче Фәнзилә Мостафина да шундый ук эчтәлектәге хатка Яңа ел ялларыннан соң Казанга килгәч тап була.

– Башта игътибар итми генә башка түләү кәгазьләре белән бергә алып куйган идем. Җентекләбрәк карагач, моның ялган кәгазь икәне аңлашылды. Дөресрәге, реклама кәгазе булуы, – ди ул. – Беренчедән, белдерүдә милек хуҗасының исем-фамилиясе дә, фатир адресы да язылмаган. Ә бит барлык рәсми квитанцияләрдә дә языла алар. Икенчедән, кәгазьне җибәргән оешма турында да ишеткән юк. Нишләп әле андый кәгазьне үзебезнең идарәче компания җибәрми, бөтенләй билгесез оешма җибәргән дип аптырадым. Шушылар шик тудырды.

Һәрнәрсәне кат-кат тикшерергә күнеккән кеше буларак, шушы хат турында да белешкән. «Үзебезнең идарәче компаниягә шалтыраттым: алар бернәрсә дә юлламаган. Без барлык белдерүләрне квитанциягә язабыз, аерым кәгазьдә килгәннәргә ышанмагыз, диделәр миңа», – ди Фәнзилә.

Тик бар кеше дә бу кадәр уяу түгел шул. Алдакчылар тәэсир итә алырдай, коткыга бирелердәй кешеләр җитәрлек. «Федераль законны да китергәннәр, таблицасы да бар. Шуңа ышандым инде. Кәгазьдәге номер буенча шалтыраттым. Барысы да тәртиптә булсын өчен, 5 мең сумлык эшләр башкарырга кирәк, диделәр, – ди Казанның Киров районында яшәүче бер ханым. – Ярый күршем – яшь кеше. «Сиңа да мондый хат килмәдеме?» – дип сорарга башым җитте. Дөреслеккә туры килмәгән кәгазь булуын әйтте. Пенсиямнең зур өлеше мошенниклар кесәсенә китәсе иде».

Нишләргә?

Оешманың, бәлки, чынлап та исәпләү җиһазларын тикшерү һәм алыштыру хокукы бардыр? Рәсми мәгълүматларга караганда, мондый эшне аккредитация узган оешмалар гына башкара ала. Һәрхәлдә, хатта күрсәтелгән оешманың андый хокукы юк булып чыкты.

> Исәпләү җиһазын тикшерү вакыты төрле счетчиклар өчен төрлечә. Мәсәлән, салкын су исәплəгечләре өчен – 6 елга 1, кайнар суга – 4 елга 1 тапкыр.

Ахыры 2 нче биттә >

Төзелеш мәйданнары арта

Узган елда Россиядә барлыгы 92,6 миллион кв. м торак мәйданы файдалануга тапшырылган. Бу – алдагы елдагыга караганда 13 процентка күбрәк. Премьер-министр урынбасары Марат Хөснуллин әйтүенчә, Советлар Союзыннан башлап, бөтен ил тарихында иң зур күрсәткечкә ирешелгән. Әлеге күрсәткеч 4,2 миллион гаиләнең, ягъни 10 миллион чамасы кешенең торак шартларын яхшырту мөмкинлеге биргән. Шул ук вакытта быел гыйнвар аенда торакны файдалануга тапшыру узган елдагы шушы ук чордагы күрсәткечтән 14 процентка артыграк. «Димәк, кыенлыкларга карамастан, барлык күрсәткечләрнең үтәлəсенә зур өметләр багларга мөмкин», – диде Марат Хөснуллин.

Балаларга – мөстәкыйльлек

Россия Хөкүмәте 14 яшьтән зуррак үсмерләргә «Дәүләт хезмәтләре» порталында мөстәкыйль теркәлергә рөхсәт итүне күздә тоткан карар әзерләгән. Ә инде 14 яшьтән кечерәк балаларны әти-әниләре үзләренең «шәхси кабинет»ында теркәячәк.

– «Дәүләт хезмәтләре» порталы үз мөмкинлекләрен даими киңәйтә, шул исәптән балалар өчен электрон сервисларны камилләштерә. Әлегә алар әти-әнисенең «шәхси кабинет»ы аша гына анда керә ала иде. Бу, әлбәттә, уңайсызлыклар тудыра. Шуңа күрә 14 яшьтән зуррак үсмерләргә системада мөстәкыйль теркәлү мөмкинлеге биргән карар әзерләнде», – дип белдерде Премьер-министр Михаил Мишустин шул уңайдан. Порталдагы «шәхси кабинет» аша электрон көндәлеккә кереп, өй эшләре, акча күчерелү турында белергә, каникул вакытында акча эшләп алу өчен гариза тутырырга мөмкин булачак.

Чаралар нәтиҗәсез

Россия Генераль прокуратурасы тикшерүе урам этләренә бәйле кыенлыклардан чыгу буенча башкарма хакимият органнарының начар эшләвен ачыклаган. Сукбай этләрнең кешеләргә һөҗүм итүен булдырмау максатында күрелгән чаралар нәтиҗәсез дип табылган. Соңгы вакытларда илнең төрле төбәкләрендә урам этләренең кешеләргә ташлануын, хәтта үлем-китемнәр китереп чыгаруын искә төшерик. Әйтик, сукбай этләр Башкортстанда – 4 яшьлек малайны, Әстерханда бер ир-атны талап үтергән. Мондый очраклар буенча җирле түрәләрнең эшкә салкын каравы турында җинаять эшләре кузгатылган. Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко да урыннарда түрәләрнең җаваплылыгын көчәйтергә кирәклеген белдерде.

Шул ук вакытта Генераль прокуратура төбәкләргә эт хуҗаларына карата өстәмә таләпләр билгеләү хокукы бирүне хуплаган.

COVID-19

Меңнән артты

Пирчәткәсез, ПЦР-тестсыз. Россиядә коронавируслы вазгыятьтә яшәү кагыйдәләре үзгәрде. Аңа карап кына чирләүчеләр һәм, ни кызганыч, үлем очраклары кимемәде.

Балалар да чирли

Татарстан Президенты уздырган «шимбә киңәшмәсе»ндә дә COVID-19 турында сүз булды. Чире дә шул, аңа бәйле яңалыклары да: сәламәтлек саклау тармагы бар көченә эшли, авыручылар саны көн саен арта. Шул исәптән балалар арасында да.

– Сырхаулар өчен 4 меңнән артык ятак бар, әлегә шуларның 2,4 меңе буш. Сәламәтлек саклау системасы бар куәтенә эшли, кызганыч, медицина хезмәткәрләре арасында да авыручылар күп. Йөкләнеш бик зур, – диде ул. Билгеле булганча, республиканың оператив штабы карары буенча, амбулатор медицина оешмалары шимбә һәм якшәмбе дә хезмәт күрсәтә. – Мәктәпләрдә балаларны «фильтр» аша үткәрү мәсьәләсен даими контрольдә тотарга кирәк. Бу үз нәтиҗәсен бирә. Аерым сыйныфларны үзизоляциягә җибәрәбез. Хәзергә 2422 класс карантинда. Шунысына да аерым игътибар итәргә кирәк: карантинда утырган балалар теләсә кайда йөрергә тиеш түгел.

«Таҗ»лы вазгыятьнең саннарына килгәндә, узган тәүлектә чир йоктырган 1305 кеше теркәлде. Шуларның 92се – балалар. 1209 кеше өйдә дәвалана, калганнары хастаханәләргә озатылган.

Коронавируска каршы вакцина ясатучылар саны 2416412гә җиткән. Шуларның 1893654е икенче дозасын алган. Кабат вакцинация узучылар – 205425 кеше.

Узган атна медицина оешмаларына чират торучыларның күплеге белән истә калгандыр, мөгаен. Республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгында сырхауханәләргә көннең икенче яртысында килергә киңәш иттеләр.

– Төштән соң чират та кими, ярдәм алу ихтималы да арта, – диде министр урынбасары Владимир Жаворонков. – Медицина оешмалары атна буе эшли. Моңа карап кына хастаханәгә ятучылар саны алай ук кимемәде. Шәһәрдә коронавируслы сырхаулар өчен 1720 ятак бар. Шуларның 16 проценты гына буш. «Ашыгыч ярдәм» хезмәтен чакыручылар саны бермә-бер артты. Бер тәүлеккә 2100–2200 чакыру кабул итәләр. Декабрьдә бу сан 1300 чамасы иде.

Яңа кагыйдәләр

Россиядә COVID-19 инфекциясе белән авыручылар һәм сырхаулар белән аралашкан кешеләр өчен яңа таләпләр кертелде. Тиешле карар 6 февральдән үз көченә керде.

Үзгәрешләр нәрсәгә һәм кемгә кагыла?

– Коронавируслы сырхаулар белән аралашкан кешеләрне карантинга җибәрмәячәкләр;

– чирдән дәвалану вакыты җиде һәм аннан күбрәк көн тәшкил итә икән, стационарларда һәм амбулатория шартларында дәваланып аякка баскач, коронавируска тест тапшырмый гына хезмәт эшчәнлеген (уку) башларга рөхсәт ителә;

– бер сыйныфта балаларның 20 проценттан артыгы авырый башласа, мәктәп укучылары читтән торып укуга күчә;

– элегрәк, коронавирустан саклану чарасы буларак, пирчәткә кию мәҗбүри иде. Хәзер исә бу чикләү чарасы гамәлдән чыгарылды.

Әмма пирчәткә кимәүдән генә чир бетми. Гади саклану кагыйдәләрен үтәү әле дә мөһим.

Сүзгә-сүз



Фирзәр МОРТАЗИН, Татарстанның халык артисты:

Бергә озак еллар яшәгән саен, бер-береңә ярашасың. Дус та буласың, ике көн күрми торсаң, сагынасың. Менә мәхәббәт шул инде ул.

(«Сөембикә» журналыннан)

ТАТАРСТАНДА – ТЕРЛЕКЧЕЛЕК

Узган ел Татарстанда 1 млн 435 мең тонна сөт һәм 411,6 мең тонна ит җитештерелгән.

СӨТ
1 млн 435 мең тонна
Бер сыерга уртача 6600 кг

ИТ
411,6 мең тонна
98,2 мең тонна сыер ите
98,6 мең тонна дуңгыз ите
212,4 мең тонна кош ите

Суык һәм кар көтелә

Татарстан Гидрометеоүзәгеннән хәбәр ителгәнчә, бу атнада җиңелчә генә суык һава көтелә. Синоптиклар аз гына кар-буран, иртән һәм төнлә томан төшүне фаразлый. Чәршәмбе – 9 февральдә республикада болытлы һава торышы хөкем сөрәчәк. Төнлә республиканың көнбатыш төбәгендә бераз кар көтелә. Көндез барлык районнарда диярлек кар, урыны белән буран булырга мөмкин. Көндезге һава температурасы −1...−6 градус, төнлә −5...−10, урыны белән −15 градуска кадәр суыта.

Пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә кар-буран, юлларда – кар көртләре. Пәнҗешәмбе көндез −3...−8 градус, төнлә −5...−10 градус булачак. Ә инде җомга көнне −1дән −6 градуска кадәр. Башлангыч фаразларга караганда, шимбә – 12 февральдә җиңелчә генә суык һава көтелә. Көндез 0 градуска кадәр җылытачак, төнге сәгатьләрдә −3...−8 градус.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АФРИКА ЛИДЕРЛАРЫ НИДӘН ЗАРЛАНА?

Үткән атнада дөнья вакыйгалары гадәтигә әйләнгән сикәлтәле эздән акты. Глобаль протест, дәүләт түнтәрелешләре, хәрби блокларның сугыш алды конфронтациясе беркемне дә гаҗәпләндерми инде. Пекин Олимпиадасы ачылу алдыннан ике зур держава җитәкчеләре – Путин һәм Си Цзиньпинның күзгә-күз очрашуы һәм уртак белдерү ясавы, мөгаен, зур тарихи вакыйга булып язылыр. Ике лидер да халыкара сәясәт мәсьәләләренә бердәм караш белдерделәр. Хәрби куәтләре ягыннан дөньяда икенче һәм өченче урыннарны бүлешүче илләрнең катлаулы вазгыятьтә аркадашлыгы зур әһәмияткә ия, билгеле. Шул ук вакытта карашларның уртаклыгы гаҗәпләндерми дә, чөнки ике ил дә башында АКШ торган глобаль коалиция белән кискен конфликтта һәм ике ил дә үз чикләре янында зур сугышка китерергә ихтимал булган катлаулы төенне чишү белән мәшгуль. Әмма уртак белдерүдә дипломатик рәвештә Украина телгә алынмады, Көньяк Кытай диңгезе проблемасын кузгатмадылар. Белгечләр моны Кытайның Украина белән, Россиянең Вьетнам белән араны бозарга теләмәве дип аңлаттылар.

Россиянең көнбатыш чигендә киеренкелек берникадәр йомшарса да, гаскәрләрнең кара-каршы хәрәкәте тукталмады әле. Украинага АКШтан һәм башка НАТО илләреннән тонналап-тонналап корал ташыла, америка гаскәрләре океан аша кичеп элекке Варшава договоры илләре туфрагында фронт сызыгына тезелә башладылар.

Дөньяда пандемия чикләүләре белән бәйле протестлар үсә. Коронавируска каршы көрәшнең алгы сызыгында булган Израильдә чир йоктыручылар саны кими, әмма каты авыручыларның үлем очраклары арта. Бу – илнең Сәламәтлек саклау министрлыгыннан алган рәсми хәбәр, фейк түгел.

Планетада турбулентлыкның көчәюе кара континент мисалында ачык күренә. Үткән ел Африкада егерменче гасырның алтмышынчы елларындагыга караганда күбрәк дәүләт түнтәрелеше теркәлгән. Алтмышынчы еллардагы киеренкелек аңлашыла, чөнки ул чакта түбәнсетелгән халыклар, колониаль изү богауларыннан котылу өчен, массакүләм көрәшкә күтәрелгәннәр иде. Бу – кан коймыйча гына хәл ителә алмый торган мәсьәлә. Хәзер янә шундый вазгыять мәйданга чыга. Эфиопия башкаласында саммитка җыелган Африка лидерлары материкта таралган фетнә дулкыныннан зарландылар. Ел дәвамында биш илдә: Буркина-Фасо, Гвинея, Мали, Судан һәм Чадта хәрбиләр фетнә ясап, хакимлекне яулап алганнар. Аддис-Абебага җыелган Африка союзының лидерлары моны гаепләделәр һәм фетнәче хәрбиләргә түзеп тормаячакларын белдерделәр. Буркина-Фасо, Гвинея, Мали, Суданның союзда әгъза булып торуы туктатылды. Африка союзы тарихында берьюлы шулкадәр илгә санкция кертү беренче тапкыр. Егерме беренче гасыр башында бу континентта фетнә тыгызлыгы берникадәр кими төшкән иде. Соңгы ике елда дәүләт түнтәрелешләре ешлыгы рекорд куя: алты илдә хәрбиләр хакимиятне кулга төшергәннәр, өч омтылыш уңышсыз төгәлләнгән. Үткән атнада гына Гвинея-Бисауда хәрби фетнә уңышсыз тәмамланды. Мондый вазгыять лидерларның кытыгына тия, әлбәттә, аларны иң куркыныч профессия вәкилләренә әйләндерә бит. Шул ук вакытта бу – Җир шары масштабында вазгыятьнең начараю билгесе дә.

Россиядә

ПРОЦЕНТ ТАГЫН КҮТӘРЕЛӘ

Халыкара киеренклек шартларында Мәскәү хәрби өйрәнүләр ешлыгын арттыра. АКШның хәрби җитәкчелеге үткән атнада Россиянең февраль уртасында атом-төш өчлеге: шахтададан, су асты көймәләреннән һәм самолетлардан атыла торган ракеталарны очырып, хәрби өйрәнүләр үткәрергә җыенуын игълан итте. Чынлыкта, океан артында атом-төш сугышы башлануын уйнап карыйлар дип шаулыйлар. ТАСС, Россиянең Оброна министрлыгындагы чыганакларга таянып, хәрби өйрәнүләрнең планлаштырылуын раслады. Төньяк флотның су асты көймәсе Камчаткадагы полигонга, Тын океандагы атом субмаринасы илнең төньягындагы Чижа полигонына континентара стратегик баллистик ракеталарны атып караячаклар икән. Моннан тыш коры җирдән дә шундый ук ракета күтәреләчәк, ерак арага оча торган авиация канатлы ракеталарны хәрәкәткә китерәчәк, ди. Андый өйрәнүләр булып тора ул үзе, янкилар бу юлы Украина белән вазгыятькә бәйләп, аны гадәттән тыш вакыйга итеп тәкъдим итәргә тырышалар гына.

Илнең эчке тормышы өчен инфляция темасы һаман да мөһим булып кала бирә. Күрелгән чараларның көтелгән нәтиҗәсе юк чөнки. Рәсми инфляция 9 процентка якынлаша. 11 февральдә Россия Үзәк банкы утырышка җыела. Бу уңайдан барлык белгечләр дә беравыздан төп ставка нык күтәреләчәк, диләр. Искә төшерик: 2021 елның мартында төп ставка 4,25 процент иде. Хәзер ул 8,5 процентны тәшкил итә. Бу санны Үзәк банк декабрьдә атаган иде. Ул чакта рәсми инфляция 8,4 процент белән бәяләнде. Үзәк банк, ставканы күтәргәч, бәяләр үсеше туктала дип раслый, әмма быелның гыйнварында еллык инфляция күрсәткече 8,9 процентка җитте. Бу атнаның җомгасында төп ставканың 9,5 процентка җитәчәгенә берәү дә шикләнми диярлек. Кайбер аналитиклар 9 процентка кадәр генә күтәрерләр дигән ышаныч белдерә белдерүен. Иске 8,5 процент та бик югары инде югарылыкка. Матди проблемаларын кредит алып хәл итүчеләр койрыгына нык баса торган. Хәзерге капитализмда бизнесның кредитсыз яшәмәвен искә алганда, икътисади үсешнең тамырына агу булып тама ставканың күтәрелүе. Әмма бер яхшы ягы бар: кредит алмыйча яшәүчеләр өчен начар түгел. Үткән ел бурычка комсызлык хәлне бик кискенләштерде бит: төзелеш материаллары инфляциясе рәсми инфляцияне күп тапкыр узып китте. Хәзер ипотека алырга теләүчеләр саны кими башлаган, диләр. Бәлки, бәяләр төшмәсә дә, кискен күтәрелүдән туктар.

Белгечләр, мартта төп ставка 10 процентка җитәр, бары тик елның икенче яртысында гына бәяләр дә узыштан туктар, төп ставка да төшә башлар, диләр. Барысы да яхшы барган очракта инде бу фаразның тормышка ашуы. Әмма дөньякүләм кризис үкчәгә басып килә, шуңа күрә вазгыять фаразларның киресе белән кайтаваз бирергә дә ихтимал.

АКЫЛЛЫЛАР ҮЗЕБЕЗГӘ КИРӘК

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия Фәннәр академиясе Казан Фәнни үзәгенең Завойский исемендәге Казан физик-техник институтында булды.

tatarstan.ru

Институт 1945 елда оештырылып, илебез фәнен үстерүгә зур өлеш кертеп килә. Фән һәм техниканың төрле өлкәләрендә радиоспектроскопия буенча төп фәнни үзәкләрнең берсе булып тора ул. Рөстәм Миңнеханов институт лабораториясендә галимнәрнең эшләнмәләре белән танышты. Алмазларда квант оптикасын үстерү лабораториясендә Президентка, квантлы информатикадан алып биотехнологияләргә кадәр, төрле кушымталар өчен яңа наноматериаллар булдыру турында сөйләделәр. Лабораториядә алынган нанокисәкчекләрне күзәнәкләрдәге шешләрне ачыклау өчен файдаланырга мөмкин. Бу, үз чиратында, яман шеш кебек күзәнәк авыруларына каршы көрәшү мөмкинлеге бирәчәк.

Лабораториянең җитәкчесе – Америка профессоры Филипп Хеммер. Рөстәм Миңнеханов, аның белән видеоэлемтә аша сөйләшеп, Татарстан фәнни үзәкләре белән актив хезмәттәшлеге өчен рәхмәт белдерде.

Татарстан Президенты биредә Федераль тикшеренүләр үзәге күргәзмә стенды белән дә танышты. Аңа табигый ресурслар, материаллар һәм технологияләр кебек юнәлешләр буенча эшләнмәләр күрсәтелде. Рөстәм Миңнеханов видеоконференцэлемтә аша озак еллар буе Казан физик-техник институтына җитәкчелек иткән Кев Салихов белән дә аралашып алды.

Президент институтта яшь галимнәр белән дә очрашты. Рөстәм Миңнеханов аларны 8 февральдә билгеләп үтелүче Россия Фәне көне белән котлады. «Илебезнең фәннән башка алдынгы була алмаячагын барыбыз да аңлыйбыз. Бездә киләчәге булган яшь галимнәр бар. Безнең алга таба фәнне үстерү буенча планнарыбыз зур», – диде ул яшь галимнәргә. Президент республикада Академик фән үзәге төзү мәсьәләсе каралуын да искә төшерде. «Бу эшнең фәнни ягы, эчтәлеге өчен академиклар җаваплы булачак. Ә без инфраструктураны үстерүдә актив катнашырга әзер. Безнең яхшы база бар. Әмма фәнни куәтебезне арттырырга кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Әгәр бездән яшь өметле галимнәр китсә, бик аяныч булачак. Киресенчә, безгә килергә омтылсыннар һәм биредә үзләрен уңайлы хис итсеннәр өчен шартлар тудырырга кирәк».

Казанда фән үсешенә зур өлеш керткән яшь галимнәрне бүләкләделәр. Республиканың иң яхшы яшь галимнәрен ачыклый торган бәйгегә быел 155 гариза килгән. Биредә Татарстанның югары һәм урта белем бирү оешмаларында укучы студентлар белән беррәттән, төрле оешмаларда эшләүче яшьләр дә катнашырга теләк белдергән. Җиңүчеләр җиде номинациядә билгеләнгән. Тантаналы чарада исә яшь галимнәргә 90, 70, 50 мең сум күләмендә премия тапшырылды.

Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов тантанада республикада яшь галимнәргә ярдәм йөзеннән махсус программа эшләнәчәген дә әйтте. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов фатихасы белән башланган әлеге эш өч өлештән торачак. «Программаның беренче өлеше – яшьләр арасында фәнне популярлаштыруны, икенчесе фәнни иҗат һәм эшләнмәләргә ярдәм итүне күздә тота. Фән тармагында кайнаган яшьләрне социаль яктан тәэмин итү дә планлаштырыла», – дип сөйләде министр. Тантаналы чарада катнашкан Татарстан Президенты ярдәмчесе Альберт Гыйльметдинов көзгә таба Татарстанның алдагы ун елга фәнни-техник үсеш стратегиясе төзеләчәген дә хәбәр итте.

Татарстанның югары һәм урта уку йортларында белем алучы иң яхшы 90 студент, адъюнкт һәм аспирантка да дәүләт стипендияләре тапшырылды. Быел иң яхшылар дип табылган адъюнкт, аспирантлар – 33 мең сумнан артык, вуз студентлары – 28 мең сум, урта һөнәри белем бирү оешмаларында укучы студентлар 17 мең сум премиягә лаек булды.

Һәр кәгазь дә түләү өчен түгел

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге» башкарма директоры Дмитрий Романов сүзләренчә, бу кәгазьләр – гадәти маркетинг алымы. Шуңа бу кәгазьгә бер күз салырга һәм... ташларга кирәк.

– Төп кәгазь – счет-фактура кәгазе, шуңа таянырга кирәк. Таблицада исәпләү җиһазларын кайчан тикшерәселәре турында мәгълүмат бар. Соңгы тапкыр кайчан тикшергәннәре турында да язылган, – ди ул. Белгеч әйтеп үткән бүлекләрнең исемнәрен язу зыян итмәс: исәпкә алу җиһазларының күрсәткечләре турында мәгълүмат «Дата последующей поверки ИПУ» дигән өлештә булыр.

Бу белдерү кәгазен реклама буларак та кабул итәргә мөмкин, дидек. Хокук белгече Ләйсән Халикова сүзләренчә, Татарстанда мондый күренешләр белән көннән-көн ешрак очрашырга туры килә. Алданмас өчен нишләргә?

– Шушы кәгазьләр ясаганда федераль законга «таяналар», кеше аңына шуның белән йогынты ясыйлар. Ягъни хөкүмәт җибәргән кәгазь бит бу дип кабул итәсең. Кәгазьдә язылганнарны мәҗбүри рәвештә үтәргә кирәк дигән тәэсир тудыралар. Мәсәлән, фатир өчен түләү кәгазьләрендә штрих-код, саннар күрәбез бит, бу да шул калыпта ясалгач, ышандыра, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләр тиз ышанучан андыйга, – диде Ләйсән Халикова. – Култамга, мөһергә игътибар итәргә кирәк. Аннан бу төр хатларда күрсәтмәләрне башкаручының исем-фамилиясе күрсәтелми. Димәк, кәгазь мәгънәсез. Гадәттә, бу кәгазьләрдә «Реклама турында»гы федераль законның 5 маддәсенең 3 бүлегендәге 20 пунктында һәм 7 бүлектә язылган таләпләрне санга сукмау күзәтелә. Бу рекламаны, гадәттә, шәхси эшмәкәрләр ясый. Республиканың монополиягә каршы хезмәте «рәсми кәгазьләр» ясап тараткан кеше-оешмаларны хокук бозу өчен җәза тартканы да бар.

Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүчеләрдә дә хәлләр шул чама икәне ачыкланды. Бичара беркатлылык җимеше инде бу. Слесарь чакыртып, күп дигәндә 500 сум түләп, счетчик алмаштырыр урынга, куркуга төшеп, меңәрләгән сум акчаны югалтуны ничек аңлатасың тагы?

Белгечләр шуны искәртә: исәпләү җиһазларын тикшертергә кирәк булса, торак милекчеләре ширкәтенә яисә идарәче компаниягә мөрәҗәгать итү хәерле. «Открытая Казань» хезмәтендә гариза да калдырырга мөмкин.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЯШЬ ГАЛИМӘ НАЗЛЫГӨЛ ГӘРӘЕВА:

«БАСУДА ЙӨРГӘННЕҢ КИРӘГЕ ЧЫКТЫ»

Шәһәр кызы Назлыгөл Гәрәева ничек итеп арышны арпадан аерырга өйрәнгән? Татар авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренү институты белгече белән фән дөньясына ничек килеп керүе, яшь галимнәргә мөнәсәбәт турында сөйләштек.

Назлыгөлгә – 28 яшь. Мәктәпне тәмамлагач, КФУның фундаменталь медицина һәм биология институтының генетика бүлегендә белем алган. Студент вакытта ук мөгаллим, биология фәннәре докторы Мира Пономарева кызның авыл хуҗалыгы өлкәсенә карата кызыксынуын күреп, аны үз янына – Татар авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренү институтына эшкә чакырган. Бүген ул көзге культуралар селекциясе бүлегендә кече фәнни хезмәткәр булып эшли. Монда килүенә алты ел узган инде. Хәзерге вакытта авыл хуҗалыгы үсемлекләре селекциясе юнәлеше буенча аспирантурада да белем ала.

– 2019 елда Татарстанда һәм Идел буе төбәкләрендә «карсыман күгәрек» («снежная плесень») барлыкка килү уҗым культураларының яртысын харап иткән иде. Бу гөмбә авыруы кар астындагы көзге бөртекле культураларга зыян китерә. Шуннан соң институтта инфекцияле авыруларга каршы көрәшү өчен лаборатория ачылды. Без анда беренче итеп тритикалене (бодай белән арыш гибриды) тикшердек. Яңа ысуллар булдырдык. Тәҗрибә тупларга мәйданчыклар җитәрлек. Лаеш районының Олы Кабан авылында институтның эксперименталь мәйданчыгы урнашкан. Төрле басуларга чыгып, үсемлекләрне җыеп, тикшерүләр үткәрәбез. Үсемлекләрнең үсеш фазалары ничек узуын, нинди авырулар яки корткычлар янавын, вазгыятьне, уңайсыз шартларны ничек итеп яхшыртып булуын өйрәнәбез. «Карсыман күгәрек» авыруына каршы препаратлар бар. Әмма тулысынча нәтиҗә бирми, – дип сөйли Назлыгөл.

2019 елда хезмәттәшләре белән бергә «Культуралы үсемлекләрдә инфекцион чирләр: «карсыман күгәрек» үрнәгендә тикшерүләр үткәрү» дигән юнәлеш буенча мегагрант отканнар. Өч ел дәвамында хезмәт хакына өстәмә акча алган. Узган ел «Киләчәк фәне – яшьләр фәне» бөтенроссия фәнни бәйгесенең финалына үткән.

– Шәһәр кызы дип аптырамагыз. Басуларда йөрергә яратам мин. Балачагым Чүпрәле районының Яңа Ишле, Иске Кәкерле авылларында узды. Мәрхүм бабаем Җиһангәрәй Алимов баш агроном иде. Үзе белән ияртеп, кырга алып чыга да үсемлекләр турында сөйли, аннан элеваторга алып бара иде. Анда ашлыкны учларыма алам. Икмәк бит бу! Бу бөртекләр бар халыкны туендырырга җитә дип горурланып куям. Миңа – шәһәр баласына бал кортлары без елдәвеннән башлап, кырда үскән күкчәчәкләр, ромашкалар, хәтта чүп үләннәргә кадәр кызык иде. Менә шунда бабай: «Кызым, монысы – арыш, ә монысы – арпа», – дип, аларны аерырга өйрәтте. Үсемлекләргә мәхәббәт шунда уянгандыр, күрәсең. Институтка эшкә керүемә бер дә үкенмим. Ел дәвамында фәнни хезмәтләр язабыз, грантларда катнашабыз, аптырап утырырга вакыт юк, – ди Назлыгөл Гәрәева.

– Яшь галимнәргә игътибар җитәме? – дип сорыйм аннан.

– Бүген грантлар күп, рәхәтләнеп катнашып, аны отарга мөмкин. Белгечләр башка өлкәләрне дә өйрәнә ала. Без, мәсәлән, химик-биологлар белән дә хезмәттәшлек итә алабыз. Әлбәттә, хезмәт хаклары күбрәк булсын иде. 20 мең сум хезмәт хакы белән генә ерак китеп булмый, – ди яшь хезмәткәр.

Сәрия МИФТАХОВА

ДЕПУТАТЛАР ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышы 10 февральдә Дәүләт Советы утырышлар залында үткәреләчәк. Башлана – 10.00 сәгатьтә. Депутатларны теркәү Дәүләт Советы бинасында 10 февральдә 8.00 сәгатьтән башлап хәл ителә. Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

ТИЗГӘ ЫШАНЫЧ ЧАМАЛЫ

Россиядә битлек, антисептик кебек саклык чараларына, коронавирусны ачыклаучы экспресс-тестларга ихтыяҗ арткан. Соңгы ун көн эчендә генә дә алар 70 процентка күбрәк сатылган. Кешенең коронавирус белән авырыймы-юкмы икәнлеген тиз арада ачыкларга ярдәм итүче экспресс-тестларга сорау аеруча зур.

Бу аңлашыла да. Чир котырган чорда үзең теркәлгән хастаханәгә барып, җайлы гына ПЦР-тест тапшырам димә. Дилбегә буе чират торырга әзер тор. Дөрес, аны шәхси клиникаларда да ясатып була. Әмма нәтиҗәсен 1–2 көн көтәргә туры киләчәк. Шуңа күрә күпләр үзлегеннән генә экспресс-тест ясап, ковид белән авырыймы-юкмы икәнлеген ачыкларга тырыша да инде. Бүген мондый тестны теләсә кайсы даруханәдән сатып алырга мөмкин.

Ун көн элек, кисәк кенә авырып киткәч, үземә дә шушы тест ярдәмендә генә диагноз куеп алдым. 780 сумлык экспресс-тест дигәнең фольга капка салынган пластик кассета, эремәле колба һәм таякчыктан гыйбарәт. Соңгысын борын куышлыгына тыгып, биш тапкыр борырга кушылган. Алга таба шушы таякчыкны теге эремәгә тидереп аласың да пластик кассета эчендәге тест-тасмага бер-ике тамчы тамызасың. 15 минуттан соң тест бер сызык күрсәтте. Миндә ковид түгел икән, дидем дә тынычландым. Ике сызык булса, диагноз расланган була.

Тиз дә, җайлы да, кыскасы. Әмма белгечләр экспресс-тест нәтиҗәләренә артык ышанып бетмәскә киңәш итә. Ник дигәндә, кайчак алар дөрес нәтиҗә күрсәтмәскә дә мөмкин икән. Казанның 21 нче шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина Галиуллина сүзләренә караганда, кеше коронавирусны бернинди билгеләрсез генә уздырган, йә булмаса, мазокны дөрес алмаган очракта экспресс-тест нәтиҗәсе дөреслеккә туры килмәскә дә мөмкин.

– Әмма, гомумән алганда, коронавирусны ачыкларга ярдәм итүче экспресс-тестларга уңай карыйм. Авырулар көннән-көн күбәйгән, хастаханәләрдә ятак урыннар тулган, лабораторияләргә эш бермә-бер арткан хәзерге шартларда безгә менә дигән ярдәмче алар. Фәлән көн эчендә ПЦР-тест нәтиҗәләре әзер булганны көтәсе юк. Экспресс-тест 15–20 минут эчендә нәтиҗә бирә, – ди табиб.

Медицина фәннәре кандидаты, табиб-инфекционист Андрей Поздняков сүзләреннән аңлашылганча, соңгы арада сатуга чыккан экспресс-тестлар, ике ел элек, әле ковид тарала гына башлаган чорда сатылганнары белән чагыштырганда, күпкә төгәлрәк эшли. Белгеч 80 процент очракта алар күрсәткән нәтиҗә дөреслеккә туры килә дип ышандыра.

– Әгәр кешедә коронавирусның барлык билгеләре була торып та экспресс-тест тискәре нәтиҗә күрсәтсә, ПЦР-тест тапшырырга кирәк. Юкса кешенең, авырмыйм икән дип, тынычлап, чынлыкта ковид белән авыруын белмичә дә яшәве бар. Коронавирус йоктырган кеше белән аралашкан, хроник чирләре булган кешеләргә дә экспресс-тест урынына ПЦР-тест тапшырырга киңәш итәр идем, – ди белгеч.

ПЦР-тест вакытында биоматериал күпкә җентекләбрәк тикшерелә. Чир молекула дәрәҗәсендә үк ачыклана. Экспресс-тест исә, гадәттә, коронавирусның шактый билгеләре күзәтелә башлагач кына төгәл нәтиҗә күрсәтә. Шуңа күрә ул чирне әле башланып кына килгән чорында «күреп» тә бетермәскә мөмкин.

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә экспресс-тестны җайлы гына кулга төшерәм димә. Әле атна-ун көн элек кенә даруханәләрнең барысында да экспресс-тест сатыла иде. Әлеге юлларны язганда элемтәгә кергән биш даруханәнең берсендә генә экспресс-тест бар булып чыкты. Анда да өч кап кына калган. Экспресс-тест булмаган даруханәләрдә исә: «Бу көннәрдә кайтырга тиеш, көтәбез», – дип ышандырдылар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

vk.com

МАТУР АПА

Сәйдә абыстай белән очрашып, Васильево шифаханәсендә ун көн бер бүлмәдә яшәвебез һич онытылмаслык бер хатирә, могҗиза булды. Аллаһы Тәгаләнең шундый юлдаш, әңгәмәдәш бирүенә бик сөендем. Берничә намазны бергә укуыбызны, киңәшләрен дә рәхмәт хисләре белән искә алам. Хәтер-хатирәләре исә күңелемдә мәңгегә урын алды.

Танылган шагыйрь, олуг шәхес Сибгат абый Хәкимнең хатыны Мөршидә апа белән бәйле истәлеген язып үтим әле. Мөршидә апа Казанның мех фабрикасында шәфкать туташы булып эшләгән. Сәйдә абыстайның да яшьлек еллары шушы фабрика белән бәйле. Мөршидә апаны хезмәттәшләре «Матур апа» дип йөрткәннәр, ул әбәткә өстенә ак май яккан күмәч алып килә торган булган, тәмләп, мактый-мактый ашаганнар. «Их, киләчәктә шушы Матур апа кебек ак күмәчләр ашап яшәсәк иде», – дип, бер-берсенә теләк теләгәннәр. «Мин фабрикада 15 яшемдә эшли башладым, эшем бик авыр иде, – дип искә ала Сәйдә абыстай. – Юеш тиреләрне күтәреп илтергә көч җитмәгән вакытларым да булды, аннан җаен таптым үзе – идәнне чиста итеп юам да, утыз-кырык тирене өсте-өстенә өеп, аркан белән тартып илтәм. Әбәт турысында, гадәттәгечә, Матур апа белән чәй эчәбез. Аның шагыйрь хатыны икәнлеген, үзенең дә шигырьләр язганлыгын белгәч, мин дә үзем язган берничә шигыремне аңа күрсәтергә уйладым. Ул шигырьләремне үземнән укытып тыңлады да: «Кая, Сибгат абыеңа да күрсәтим әле», – дип, үзе белән алды. Һәм берникадәр вакыт үтүгә: «Шигырьләрең газетада басылды, менә гонорары», – дип, 30 сум акча сузды. Мин ул шигырьләрнең дөнья күрмәгәнен беләм, басылган булса, газетасын да алып килер иде. Мөршидә апаның мине илһамландыруы, шәфкать туташының шәфкатьлелеге иде бу. Матур апа мине менә шулай үз кызы кебек якын күреп, кайгыртып-үсендереп торды. Яхшылыгын мәңге онытасым юк. Байтак гомер узгач, бер аш мәҗлесендә очраттым мин Матур апаны. Елый-елый рәхмәтләремне әйттем. Урыны җәннәттә булсын, Раббым! Хәзер дә бер догадан да калдырганым юк, илаһи нур итеп йөрәгемдә йөртәм».

Сәйдә абыстай үзе сөйләде, үзе күз яшьләрен тыя алмыйча рәхәтләнеп елады. Аның белән бер бүлмәдә яшәү үзе бер рәхәтлек булса, шифаханә тирәсеннән әйләнеп кайтканнан соң аның кулына себерке алып, юлларны, сукмакларны чистартуы, һәр милләт вәкиле белән яратып, үз күреп аралашуы – могҗиза. Моның өчен шифаханә хезмәткәрләре, ял итүчеләр рәхмәт укыды аңа. Мөршидә апа кебек үк, ул да – Матур апа.

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

Икесенә – бер келәшчә...

Совет чорында һәр авылның алтын куллы осталары, нәрсәгә тотынса, шуны булдыра торган кешеләре булган. Гасырларга җитәрлек йортлар төзегәннәр алар, затлы сандык, бала бишеге, бизәкле шкаф, урындык, ат чанасы, арба, мичкә ясаганнар, кирпеч сукканнар – барысын санап бетерерлек тә түгел. Авылларда им-том итүчеләр, өшкереп, сөлек салып дәвалаучылар да бар иде әле.

Беркөнне Болгарда авылдашым Әсхәт Галиуллинны очраттым. Гаиләсе белән Дала Йорткүлендә яши ул. Тимер эшен дә, агач эшен дә булдыра торган егет, кулыннан килмәгән эше юк. Үзенең пилорамасы бар, такта ярдыра, төзелештә куллана торган күп төрле материаллар җитештерә, халыкка рәшәткәләр ясап сата, утын белән тәэмин итеп тора. Мәрхүм әтисе Минзаһит абый да булдыклы, бик тырыш кеше иде, Чәчәкледә никадәр кешегә сандык кебек йортлар төзеп бирде. Гомере буе элеккеге «Кызыл йолдыз» колхозының балта осталары бригадасында эшләде. Мин аның авыл кешесе өчен бик үк хас булмаган бер шөгыле турында ишеткән идем. Дөрес, моны шөгыль дип тә әйтерлек түгел. Баштарак ышанмаган да идем. Шуңа күрә улы Әсхәттән сораштырасы иттем.

Чыннан да, Минзаһит абый авылдагы байтак кешенең сызлаган тешен суырып җибәрә торган булган.

– Күзгә төртсәң дә берни күренмәслек көзнең караңгы, яңгыр сибәләп торган төнендә капканы шакылдата башладылар, – дип искә ала Әсхәт. – Эт буылып өргәч, әти, пәлтәсен элеп, тышка чыгып китте. Озак та тормый керде бу, артыннан ук аръякта яшәүче Рәфыйк абый Галимов та кереп җитте. Теше үтереп сызлауга түзәрлек чамасы калмагач, әти янына килгән. Уң як яңагы бераз шешеп тә чыккан әле, йөзе дә кызарыбрак киткән моның. Әти аны урындыкка утыртты, үзе исә кулын сабынлап юып килде. Ут яктысынарак китереп, авызын ачтырып карауга ук: «Хәзер, шалт иттерәбез моны!» – дип, Рәфыйк абыйның иңбашыннан чәбәкләп куйды.

Мин әтинең Рәфыйк абый тешен ничек суырганын карап тормадым, тик өйалдына чыгып китәр алдыннан аның стенадагы шкафтан үрелеп, аракы шешәсен алганын күреп калдым. Куркуны һәм авыртуны басар өчен бераз салып бирә иде ул. Әлбәттә инде, теш суыра торган келәшчәсен дә аракы яисә «Тройной одеколон» белән яхшылап сөрткәнен хәтерлим. Тышта озак тормадым, мин кергәндә инде әти, кем әйтмешли, «эш»ен бетереп тә куйган иде. Кай арада шулай өлгергәндер, үземнең дә исем китте. Рәфыйк абый да үзе белән «на всякий случай» дип чирек литрлыны кыстырып килгән булган икән. Бераз вакыт узгач, аның теш сызлавы туктады, әти белән ишегалдына чыгып һава сулап керделәр дә өстәл янына килеп утырдылар. Мин инде йокларга яткан идем, әтинең Рәфыйк абыйдан: «Авыртмыймы, башың әйләнмиме?» – дип сораганын гына ишеттем, башкасын хәтерләмим...

Минзаһит абый авылның байтак кешесен теш сызлау бәласеннән коткарган. Хатын-кызлар, хәтта әбиләр дә аның янына ярдәм сорап килә торган булган. Гади генә авыл өендә, тиешле шартлар булмавына да карамастан, берәүне дә кире борып җибәрмәгән ул, мөмкин булганда барысына да ярдәм итәргә тырышкан. Әлбәттә инде, катлаулырак тешләргә орынмаган. Келәшчәсен дә кайнатып-нитеп тормаган, одеколон яисә аракы белән генә сөртеп зарарсызландырган. Иң гаҗәбе шунда: ник берәүгә инфекция эләксен. Искиткеч!

Әле тагын шул урамда гына яшәгән, инде күптән гүр иясе булган сугыш һәм хезмәт ветераны Нурислам абый Хуҗин да теш суыргалаган. Дөрес, Минзаһит абый кадәр булдыра алмаган. Әмма ул да килгән кешеләргә ярдәм итәргә тырышкан. Кулы җиңел иде, дип сөйләгәннәрен үземә дә ишетергә туры килде. Теш суырырга кайда һәм кемнән өйрәнгәнен белмим, әмма ул келәшчәне һәрчак Минзаһит абыйдан сорап торган. Кыскасы, икесенә бер келәшчә белән эш иткәннәр.

Тәлгать ҖАМАЛЕТДИНОВ

ГАРМУНДА ИКӘН ХИКМӘТ!

Халкыбызга Рөстәм Вәлиев исеме яхшы таныш. Милләтебезгә, мәдәниятебезгә мөнәсәбәтле тантаналарда, затлы, дәрәҗәле концертларда да аның урыны гел түрдә иде. Ихластан, җырчының һәр хәрәкәтен, авазларын, бармакларына оста тотып алып, бөтен барлыгы белән гармунын сыздыручы, куе бөдрә чәчле, мыек астыннан елмаючы бу музыкантны берәү белән дә бутау, игътибарсыз калдыру һич мөмкин түгел. Рөстәмне сәхнәгә чыккан көннәреннән үк күзәтеп, иҗаты белән танышып баручы һәм аның һәр уңышына шатланып яшәүче тамашачыларның берсе мин.

Илле яшьлек юбилей тантаналары да хәтеремдә яхшы саклана. Үзе өчен дә, халкыбыз өчен дә ул онытылмас бәйрәм булды. Әти-әниләребез, гомер көзенә кереп баручы безнең буын белеп, ишетеп калган виртуоз музыкантларны, атаклы баянчыларны хәтеребездә яңартырга шәп форсат тапты юбиляр. Фәйзулла Туишевтан башлап, Гали Җәмлиханов, Рәшит Мостафин кебек гомерләре буена сәхнә тоткан барлык гармунчыларның фоторәсемнәрен экранда күрсәтеп, хәтер яңартты! Таныш йөзләрне күргәч, ерак яшьлегебезгә кайткандай булдык. Үзенә кадәрге яшәп, иҗат иткән, шактый авыр гармуннарын иңнәренә асып, татарларыбызга хезмәт иткән остаз-баянчыларны барларга күңеле җиткән иде Рөстәмебезнең.

Юбилей кичәсенең тагын бер бүләге – һәвәскәр баянчыларга да халык белән аралашу, фойеда тамашачыны гармун уйнап каршылау, тәнәфестә күңел ачтыру рәхәтен бүләк итте Самара ягы егете Рөстәм Вәлиев. Яшьләре 60–70тән узган гармунчылар рәхәтләнде уйнап үзебезнең халык көйләрен. Концерт залына үткәнче үк күңелләр гармун моңнарына кинәнде. Яраткан баянчымның иҗат кичәсен мин гармунга, халык иҗатына мәдхия дип кабул иттем. Рөстәм Вәлиевтәй музыкантлар барында, юк, бетми әле гармун, онытылмый әле халкыбыз көйләре дип, сөенеп кайттым.

Синтезаторлар, чит илләрдән кайтарылган музыка кораллары модага кергән 1970–1980 елларда булыр-булмас җырчылар «гармунчының кирәге калмады инде хәзер, гармунга кушылып җырлау – искелек калдыгы» дип әйтүдән дә тартынмады. Сәхнәләрдән, мәҗлесләрдән, зур кичәләрдән гармун берара шактый кысрыкланды. Гармун уйнап тормыш алып барып булмый, аңа ихтыяҗ кими бара дип, башка юлны сайлаучы музыкантлар да булмады түгел. Әмма яшьтән сайлаган шушы юлына тугры калган, гармунын бүтән бернәрсәгә дә алмаштырмаганнар бүген сәхнә түрендә. Ничәмә-ничә гасыр буена халкыбыз күңелен сугарган гармун моңнарын тиз генә онытмырырсың, бар...

Йөзләгән төр музыка инструментлары тавышын чыгару мөмкинлеге булган, Италиядән махсус кайтарткан ак баянын татарча сыздырды, моңландырды Рөстәм чордаш. Күпкырлы иҗатының тагын бер тармагы – көйләр язуына да шаһит булдык. Гомер бәйрәменә иҗатташ дуслары Илһам Шакиров белән Әлфия Афзалованы чакырып җырлатуы да безгә бәйрәм өстенә бәйрәм булды. Халык аягүрә торып каршылады, исемнәре әйтелүгә үк, алкышларга күмде сәхнә йолдызларын. Шушыңа күңеле җитүе өчен Рөстәм Вәлиевкә аерым рәхмәтле калдык.

vk.com

Юбилей кичәсе буена йөрәкләребез «Яшәсен гармун!» дип типте. Татарның атаклы гармунчысы белән зур концерт залларында кабат-кабат очрашулар насыйп булсын, үтә гади, шул ук вакытта ифрат затлы башкаручы Рөстәмебезгә озак еллар сәхнә тотарга насыйп булсын дигән теләктә таралыштык юбилей тантанасыннан.

Әмма тормыш катлаулы, без дигәнчә генә түгел шул. Талант иясе Рөстәм Вәлиев белән мәңгелеккә хушлашуыбызга да байтак вакыт узды инде. Әмма таланты, ул калдырган рухи байлык мәңгелек. Иншалла, яшь буын да аннан үрнәк алыр, буыннар чылбыры ныгый гына барыр.

Вәсилә РӘХИМОВА,
матбугат ветераны

КАРЫ ГЫНА БУЛСЫН, КӨРӘГЕ ТАБЫЛА

Быел, Аллага шөкер, кар мулдан. Иген кырларында, урамнарда, ишегалларында да җитәрлек. Чистартып, көрәп кенә өлгер. Хәтерлим, Кукмара районының Татар Толлысы авылында башлангыч классларда укыган чагым иде, кар көрәргә көрәк таба алмый азапландым, менә шунда әнинең ипи көрәге исемә төште. Әни, мичтә ипи пешкәч, көрәге белән ипине мичтән алып, ипләп кенә мендәр өстенә тезеп, тастымал белән каплап куя иде. Әнинең менә шушы көрәге белән мин, аның үзенә әйтмичә генә, кар көрәргә керештем. Әни күреп алды да мине нык тиргәде, һәм миңа сабак булды. Тактадан ясалган көрәкләр күргәнем бар иде, мин дә кулга балта, пычкы, чүкеч, кадак алдым. Ярыйсы гына килеп чыкты кебек. Тора-бара фанердан киң кар көрәге ясадым, көрәк очына калай кактым. Пластмасса көрәк барлыкка килгәнчә, үзем ясаганнарыннан файдаландым. Хәзер исә эш кораллары берсеннән-берсе уңайлы. Эшкә дәртең сүнмәсен дә, кесәңдә акчаң гына булсын!

Мансур ХӘСӘНОВ

Чегәннәргә карашым үзгәрде

Җәй көннәрен күбрәк бакчада уздырырга яратам, тавыклар белән сөйләшәм, бакчадагы кошлар белән ярышып сызгырам, җырлыйм. Үз ана телемдә сөйләшеп мәш киләм. Мин аның нинди кош икәнен дә белмим, сандугач кебек кечкенә генә кошчык бар. Ул ел саен безнең бакчага әйләнеп кайта.

Бездә бит өйдә сызгырырга ярамый, мин шуңа күрә бакчага чыгып сызгырам, бигрәк тә «Салкын чишмә» көен. Мин сызгыра башлауга, минем яныма килеп, койрыгын өскә күтәрә дә сызгырырга тотына. Аннан соң без, аның белән икәүләп, ярышып сызгырырга тотынабыз. Хәтта шушы кошлар да безнең эчке дөньябызны уртаклаша, сәнгатебезне ярата, телебезне аңлый кебек. Мин моны уйлап кына чыгармыйм, бу чыннан да шулай. Чөнки мин, суверенитет дип чабып йөргәндә, бер яшел попугай алып, аны татарча сөйләшергә өйрәткән идем. Чип-чиста итеп сөйли иде. Һаваны – «хава», һәмне «хам» диде. Ул үлгәч, балалар күз яшьләре белән еладылар. Бик авыр булды аны югалту. Хәзер инде аласы килми, авыр кичердек.

Көн буе шушы бакчамда йөрим, җырлыйм, яшьлегемне искә төшерәм, үземне шушы бакчада үз дәүләтемдә йөргән кебек хис итәм. Әле үзенә күрә флагым да бар. Тик менә җәйнең иң рәхәтен, матурлыгын чебен-черки боза, иң яратмаганым шул. Чебен-черкидән котылыр өчен, бер көнне Казандагы сәүдә үзәгенә юнәлдем.

Бардым. Карый торгач, таптым мин бу сетканы, төсе дә, размеры да килә. Кулыма алып карый башлаган идем, янымда бер кеше пәйда булды, хуҗасы икән. «Ничек соң, ошыймы, күпме кирәк?» – ди. «Күпме тора?» – дим. «Төргәге мең ярым тора», – ди. Хакы юнь икән, кесәмдә акчам бар иде, Аллага шөкер. Мин, санап, тиешле бәясен бирдем. Ә ул акчаны санап карады да миңа мең ярым акчаны кайтарып бирде. «Мин бит сиңа дөрес бирдем, нигә акча кайтарып бирәсең?» – дидем, аптырап.

«Абзый, миңа кеше акчасы кирәкми, мин гөнаһтан куркам, тиешлесен генә бир», – диде, русчалатып. 2 мең сум белән 200 сумның төсе охшаш булгач, мин ялгышканмын икән... Кызыксынып, милләтен сорадым. «Мин – чегән, Урта Азия чегәне», – диде ул. Рәхмәтемне әйтеп, кайтып киттем. Шул хәлдән соң чегәннәргә карата да карашым үзгәрде. Ә бит аларны элек-электән кеше алдаучылар, караклар дип йөртәләр иде.

Менә сиңа мә!

Шамил ӘХМӘТҖАНОВ

«Перекоп»лы яшьлегебез

Узган гасырның сугыштан соңгы елларында Кукмара халкы «Перекоп» исемле кинотеатрга, өелешеп, кино карарга йөрде. Ул иксез-чиксез чират дисеңме, ул этеш-төртешләр Кукмараның бердәнбер ипи кибетендәге чиратны хәтерләтә иде.

Әйтергә кирәк, төннәр буе чиратта торып, иписез калучылар да булмады түгел. Ипи кайгысын онытып, кино караучыларга, әйтерсең киномания чире йоккан. Хәтта чиратны тигезләп тәртип саклаучы милиция хезмәткәрләренең көче җитмәгән чаклар да булгалады.

Нинди фильмнар карадык соң без ул елларда? Әлбәттә, Бөек Ватан сугышы турындагы «Падение Берлина», «Молодая Гвардия». Беренчесенең бер эпизоды исемнән чыкмый. Җиңү көненә Сталин Берлинга очып төшә һәм Совет халкын бәйрәм белән котлый. Меңләгән хәрбиләр ППШ автоматларын күтәреп, «Ур-ра, Ур-ра, Ур-ра»ны яңгыратып салют бирәләр. Бу – ялган киноэпизод. Сталинның үз кабинетыннан һәм дачасыннан чыкмый торган гадәтен халык соңрак белә башлады.

«Перекоп» кинотеатрына берзаман «Тарзан» фильмы килде. Ул чорда чиксез популяр фильм. Күкрәк тавышы белән джунглины яңгыратып, Тарзан дусты Читаны чакыра. Тегесе, ботактан ботакка, агачтан агачка сикереп, Тарзан янына ашыга. Тарзан үзе дә, агачтан агачка сикереп, Кукмара тамашачысын таң калдыра иде.

Ә инде драматик һәм сәеррәк сценарийлы мәхәббәт темасы белән сугарылган Һиндстан фильмнарын Кукмара хатын-кызлары еламыйча карый алмады. Үкси-үкси елап утыручыларны да күрдем мин. Алар елаганда мин көлә идем. Нишлисең бит, маңгайларына тамга сугылган чибәркәйләр – актрисалар һәм кара йөзле, кара күзле артистлар мәхәббәтнең нәрсә икәнен күрсәтә беләләр иде үзләренчә. Радж Капур җырларының берсе «Абарая» («Бродяга я») җырын Кукмара урамнарында җырлап йөрүчеләр дә булды.

«Перекоп» кинотеатры хәзерге Ленин урамындагы район хакимияте урынында урнашкан зур, бер катлы агач бина иде.

Алгы ягында зур хәвефле «Перекоп» дигән язу балкып тора иде. Ә инде «перекоп» дигән сүзнең сере һәм нигезе халкыбызның мәшһүр классик язучысы әдип Гомәр Бәшировның «Сиваш» исемле тарихи әсәрендә ята. Сиваш – Кырым татарлары сүзе. Тәрҗемәсе – пычрак, сазлык.

1941 елның көзендә Кырым ярымутравы белән материк арасында Совет Армиясе немец гаскәрләренә каршы дәһшәтле сугыш алып бара. Сугыш белән рәттән меңләгән хәрбиләребез, билдән сазлыкка кереп, казу эшләрен башкара. Алар арасында йөзләгән татар егетләре дә була. Боларны нигә хәтергә төшердек соң әле? Безне үстергән, тәрбияләгән чор ул һич онытылырга тиеш түгел.

Рафис ПЕТРОВ

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Хезмәттәшебез, «ТАИФ» акционерлык җәмгыятенең финанс-икътисад идарәсе башлыгы Тесленко Дмитрий Ивановичның 61 нче яшендә фаҗигале төстә гомере өзелде.
«ТАИФ» идарәче компаниясе» акционерлык җәмгыяте компанияләре төркеме коллективы,
Дмитрий Иванович Тесленконың
һәлак булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Дмитрий Ивановичның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Моратовлар гаиләсе, танылган журналист, Казан федераль университеты укытучысы
Константин Курановның
вафат булуына бәйле рәвештә, аның туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

«Сөембикә» журналы редакциясе коллективы, абыйлары
Фидельнең
вакытсыз вафат булуы сәбәпле, «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Лариса Маликованың һәм сайт мөхәррире Камилә Димөхәммәтованың, аларның якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

Спорт

instagram.com

Җиңү алып килә Камилә

Дүшәмбе иртәсе күңелле яңалыктан башланды. Россия фигуралы шуучылары Пекин Олимпиадасының команда ярышларында җиңү яулады. Чемпионнар арасында Казан кызы Камилә Вәлиева да бар.

Команда ярышларында ялгыз шуучы ир-атлардан – Марк Кондратюк, хатын-кызлардан – Казан кызы Камилә Вәлиева, парлы шууда – Анастасия Мишина һәм Александр Галләмов, бозда биюдә – Виктория Синицина һәм Никита Кацалапов чыгыш ясады. Спортның әлеге төрендә Россия командасының алтынсыз калмаячагын алдан ук фаразладылар. Яшерен-батырын түгел, иң зур өметләрне якташыбыз Камилә Вәлиевага баглаганнар иде. Үз канаты астындагы спортчыларны артык мактарга яратмаучы Этери Тутберидзе да аны «артык талантлы кыз» дип атады. Ә татар кызы, үз чиратында, тренерының бу сүзләрен аклады. Кыска программада Вәлиева, барлык элементларны да чиста башкарып, 90,18 балл җыйды һәм җиңүе белән Россия җыелма командасына турнирның гомуми зачетында АКШны узып китәргә ярдәм итте. Американың фигуралы шуу остасы Карен Ченга, тупас хата җибәрү аркасында, бары тик бишенче урын белән генә канәгатьләнергә туры килде. Соңыннан исә Карен Камиләгә карап соклануын яшермәде. Хәер, Казан кызының чыгышын барлык көндәшләре аягүрә басып алкышлады. Бары Украина спортчылары гына урыннарыннан селкенергә базмады.

Дүшәмбе узган ярышлар исә Россия халкын иртәнге 4.00 сәгатьтә үк (Пекинда ул чакта сәгать 9.00 иде) уянырга мәҗбүр итте. Команда турнирының хәлиткеч ярышлары берәүне дә битараф калдырмады, ахры.

Боздагы тәүге адымнарын Казанда ясаган 15 яшьлек Камилә Вәлиева Олимпия чемпионы статусын ярышка чыкканчы ук алган иде инде. Чөнки безнең спортчыларның беренчелекне яулавы турнир тәмамланганчы ук билгеле булды. Беренче булып чыгыш ясаган Александр Галләмов белән Анастасия Мишина парлы шууда егылып, җанатарларын бераз куркытса да, эшнең ахыры имин булды. Ә инде Никита Кацалапов һәм Виктория Синицина чыгыш ясаганнан соң, турнир тәмамланганны көтәсе дә булмады. Җыелма команданың алтын медаль яулавын белгәч, Камиләбез дә бозга иркен сулап чыккандыр, җанатарлар да матур чыгыштан ләззәтләнеп кенә утыргандыр.

Ә аның чыгышы, чыннан да, гаять матур һәм катлаулы иде. Бу сезонда дөнья күләмендә рекорд артыннан рекорд куйган татар кызы Олимпия уеннарында да дүртле сикерү һәм дүртле тулуп ясый алган беренче фигуралы шуу остасы булды. Гаять катлаулы элементлардан торган чыгышы вакытында егылса да, кызның балларын киметмәделәр. Нәтиҗәдә ул үзеннән алты яшькә өлкән япон кызы Каори Сакамотоны 30 баллга артта калдырып (Камиләнең гомуми баллы – 178,92), күз яшьләре түгеп, беренчелекне алды һәм тәүге тапкыр Олимпия чемпионы булды. Беренчесе һәм соңгысы булмасын! Чөнки хәзер Камиләне шәхси ярыш көтә. Анысы 15 һәм 17 февральдә узачак. «Олимпия чемпионы буласымны әниемә 3 яшьлек чагымда ук әйттем. Менә хыял тормышка ашты. Хәзер тагын бер хыялым тормышка ашсын өчен тырышачакмын», – диде 15 яшьлек кыз.

> Казан кызын җиңүе белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады һәм аңа телеграмма юллады. «Кадерле Камилә! Татарстанда фигуралы шууны яратучылар исеменнән, шәхсән үз исемемнән сине Олимпия чемпионы исеменә ия булуың һәм иң дәрәҗәле ярышларда тәүге тапкыр җиңү яулавың белән эчкерсез котлыйм, – диелә котлауда. – Ялгыз шууда беренчелекне яулау, һичшиксез, бик зур осталыкны күрсәтә. Ә инде җыелма команда составында сокландыргыч чыгыш ясау – үз алдыңда, бөтен команда алдында гаять зур җаваплылык та әле ул. Син бу сынау алдында да каушап калмадың: Россия җыелма командасының алтын медальләре санын ишәйтеп, Олимпия уеннарында ялгыз шуучы хатын-кызлар арасында иң катлаулы – бозда дүртле сикерү ясый алган тәүге спортчыга әйләндең. Шушы зур җиңүеңнән алган хисләрең үзеңә алга таба да зур җиңүләргә этәргеч бирсен! Безнең яшь боз патшабикәсе, бары тик алга! Жюри әгъзалары өчен – нәфис һәм тел-теш тидергесез, көндәшләрең өчен – буй җитмәслек дәрәҗәдә, фигуралы шууга мөкиббән киткән миллионнарча кеше өчен, гүя гүзәллегең белән тылсымлап, бары тик син генә чыгыш ясый аласың. Уңышлар сиңа!»

Дөрес, әлеге җиңүдән соң фигуралы шуу җәмәгатьчелегендә бәхәс чыкты: тренерлар, кыска һәм ирекле программаларда бозга бер үк спортчыларны чыгарып, дөрес эшләгәнме? Имеш, ярышның беренче өлешендә алга чыккач, икенчесендә лидерларны ял иттерсәләр, башка спортчыларның да алтын медаль оту бәхетенә ирешү мөмкинлеге булыр иде. Тик бу – мәсьәләнең бер ягы гына. Әйтик, Камилә ярышмаган очракта, аның урынына бозга кемне чыгарасың: Александра Трусованымы, әллә Анна Щербакованымы? Ахыр чиктә барыбер берсе медальсез калачак, отканы исә алтынны ярышып түгел, ә катнашып алган булып чыга иде. Кыскасы, туй үпкәсез узмый, кайсының көчлерәк икәне исә шәхси ярышта ачыкланачак.

P.S. Пекин Олимпиадасында Лениногорск егете, 18 яшьлек Данил Садриевка да уңыш елмайды. Ул Ирина Аввакумова, Ирма Махиня һәм Евгений Климов белән берлектә трамплиннан сикерү буенча катнаш команда ярышларында көмеш медаль яулады.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

УТТАН АЛМЫЙ, СУГА САЛДЫҢ, УЛЫМ...

Суд залыннан

Ана күңелендә баласына карата чиксез мәхәббәт хисләре тугыз ай дәвамында йөрәк астында йөрткәндә үк ералып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Шулай булмаса, тугызынчы дистә белән баручы Гөлниса әби озак еллар дәвамында күп төрле җәбер-золымнар күреп тә, Лаеш районы суды барышында үкси-үкси елап, улын гафу итүләрен үтенмәс иде.

Судларда каралучы гыйбрәтле хәлләрдән соң җаныма урын таба алмаган чаклар еш була. Бу юлы да ак яулыклы татар әбиенең елаудан шешенеп беткән йөзе, дөньяга карата рәнҗүле, өметсез карашы күз алдымнан озак китмәде. Гөлниса әбинең төп таянычы, бердәнбер өмете улы булгандыр, күрәсең. Кояшым сүнде, ди. Тугыз елга ирегеннән мәхрүм ителгән улын төрмәдән көтеп алуына да ышанычы зур түгел инде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Судтан соң берничә ай узгач, Лаеш районының Сокуры бистәсендәге ул яши торган кечкенә генә йортны эзләп таптым. Башкаларга гыйбрәт булыр дип, Гөлниса әби башыннан узган хәлләр турында сөйләргә ризалашты.

Саба районы Шәмәрдән бистәсендә туып-үскән Гөлнисаны язмыш җилләре Казахстанның төньягына урнашкан Мәмәткә авылына илтеп адаштырганда аңа әле унбиш яшь тә тулмаган була. Җәй көне кунакка кайткан әнисенең бертуганы Рауза апа сеңлесенең берьялгызы биш бала үстерүен күреп, гаиләгә бераз булса да җиңеллек килмәсме дип, Гөлнисаны үзләре янына алып китә. Гаилә башлыгы Исхак исемле казах кешесе үзләренең алты баласы өстенә җиденчесен сыйдыруга бик теләп ризалаша.

Ачык йөзле, шат күңелле авыл кызы аш-су әзерләргә, өй эшләренә оста булуы өстенә, бакча эшләрен дә яратып башкара. Буй җитеп килүче чибәр кыз тора-бара җизнәсенең күпсанлы кардәшләренең яраткан туганына әйләнә.

Авылдан 30 чакрымдагы район үзәгендәге һөнәри-техник училищега укырга керүенә дә каршы булмый алар. Үз көнен үзе күрер, тегүчелек эше тормышта гел кирәк, диләр.

Шулай матур гына укып йөргән көннәрендә язмыш аны җизнәсенең бертуган энесе – тәртипсезлеге белән авылда даны чыккан Иманкул исемле ир-ат белән очраштыра. Үзеннән берничә яшькә олы егетнең әледән-әле сугышып, берничә тапкыр төрмәгә утыра язып калуын да ишеткән була югыйсә. Тик егетне артык якын җибәрмәсә дә, апасы белән җизнәсен үпкәләтмәс өчен, дорфа сүзләр белән яныннан кумый. Тегесе исә ял көннәрендә кызның кунакка кайтуын белеп, юк-бар сәбәп белән күрешергә җай таба.

Ни хәл итәсең, язмышың бер чуала башлагач, аңа каршы бару җиңел түгел, күрәсең. Яшьлек бит… Гөлниса кичләрен иптәш кызлары белән клубка чыкканда Иманкул озата да кайткалый. Һәрвакыт үзенекен итәргә күнеккән егет өйләнергә теләвен әйткәч, кыз бала аны шаярта дип белеп, көлә генә. Күңеленә якын булмаган кеше белән гаилә корып булмавын яхшы аңлый. Шәмәрдәндә бергә үскән егетем бар, дигәч, Иманкулның тәмам ачуы чыга. Февраль аеның салкын кичендә уналтысы да тулмаган кызның ай-ваена карамыйча, үзе кебек берничә башкисәр белән Гөлнисаны урлап китәләр.

– Хәзерге акылым булса, бикле келәтләрен тиз ачарлар иде. Апа белән җизнинең үгетләвен дә тыңламаган булыр идем, – ди Гөлниса әби, авыр сулап.

Рәнҗү, җәбердән башланган тормышның дәвамы да шундыйрак булып чыккан, күрәсең. Гөлниса, кем әйтмешли, чәче белән җир себерсә дә, Иманкул нинди дә булса гаеп таба. Тора-бара кул күтәрә башлый.

– Баштарак Рауза апама барып сыена идем. Гел генә аны да борчыйсым килмәде. Тешемне кысып булса да түздем. Балабыз тугач, басылыр, алай ук котырмас әле, дип өметләндем, – дип искә ала ул елларны Гөлниса әби.

Тик хәлләр уллары тугач та үзгәрми. Иманкул әледән-әле дус-ишләре белән күңел ачып, соңыннан сугышып-кыйнашып йөргәч, ниһаять, «теләгенә» ирешә. Үзен өч елга ирегеннән мәхрүм итәләр.

– Ул төрмәдән чыкканда улыма дүрт яшь иде. Мәктәптә җыештыручы булып эшләп йөрим. Котылып кайтуының икенче көнендә, мәктәп директоры белән чуалгансың, дип, бөтен җиремне кара яндырганчы кыйнады. Атнадан артык өйдә дәваландым. Гариза язсам, янә утыртачаклар иде. Үзе дә бераз шүрләде бугай, башка сукмам, дип ант итте. Бер ай да үтмәде, янә шундый хәл кабатланды. Улым Заһирны алып, туган якларга кайтып китүдән башка чарам калмады.

Ялгызына туган якларга кайтып төпләнү дә җиңел булмаган. Төп йорттагы энесе: «Апа, үзебездә тор. Эшен дә табарбыз», – дисә дә, берничә атнадан уңайсыз була башлаган. Үзләренең дә өч бала бит. Эше дә тиз генә табылмый. Әле теге, әле бу сәбәп табып, кире боралар. Аптырагач, Казанның Идел буе районында эшләүче энесе Рамил чакыруы буенча, Гөлниса йортлар идарәсенә дворник булып урнаша. Озакламый кечкенә генә бүлмә бирәләр.

Ялгыз анага Казан шәһәрендә торырга урын, эшләргә эшен табып, үз тормышын җайлап җибәрергә җиңел булмагандыр, билгеле. Янымда улым булмаса, шулкадәр авырлыкларны җиңеп чыга да алмаган булыр идем, дип искә ала ул көннәрен Гөлниса әби.

23 яшеннән ялгызы калып, яшьлек чибәрлеген югалтмаган Гөлнисага сүз катучы ир-атлар да булган. Шәмәрдәндәге яшьлек дусты Казанда аны эзләп табып, берничә тапкыр гаилә кору турында тәкъдим дә ясаган. Тик улы Заһир әллә кечкенә чагында әтисенең кансыз кыланмышларын хәтеренә сеңдереп калганга, әллә ялгыз калудан куркып, әнисен беркем белән дә бүлешергә теләми. Әнисе янәшәсендә ир-ат күрсә, ниндидер көнләшүгә хас борчылу белән ачыргаланып елый башлый. Шундый хәлләрдән соң каты авырып киткән чаклары да була.

Гөлниса әбинең фотоальбомын карап утырганда, Заһирның төрмәгә утырыр алдыннан төшкән фотосына игътибар иттем. Заһир… әтисе Иманкулга гаҗәеп нык охшаган икән.

– Заһирны начар гадәтләрдән никадәр генә сакларга тырышып үстерсәм дә, төс-кыяфәте генә түгел, холкы да – әтисенеке. Бүрене бүреккә салсаң да, урманга тарта, диләр. Никадәр акча түләп, укытырга тырышып карадым. Башы да эшли үзенең. Урам күбрәк тартты. Өченче курста ташлады. Эшкә урнашып, бераз эшли дә, әле теге ягы, әле бу ягы ошамый. Ташлый. Дуслары да үзе кебегрәк булды. Бераз салып алалар да маҗара эзләп йөри башлыйлар. Ике тапкыр өйләнеп карады. Хатыннарын да гаепли алмыйм. Әлфия киленем бүген дә килеп йөри. Алтының алтын булмагач, кемне дә гаепләп булмый.

Гөлниса әби күргәннәрне китап итеп язарлык икән шул. Сиксән бер яшенә җитеп, аның бер генә тыныч көне булмаган бугай. Өстәл өстендәге кочак-кочак суд кәгазьләре дә улының «шуклык»лары турында сөйли. Улының бурычларын түләү өчен Казанда егерме ел дворник булып эшләп алган ике бүлмәле фатирын сатарга туры килә. Шул еллар эчендә Гөлниса әбигә дүрт тапкыр судта булырга, ике тапкыр төрмә юлын таптарга туры килгән. Айлар, еллар дәвамында пенсия акчасының күп өлешен төрмәдәге улы өчен тоткан. Заһиры котылып кайткач та, тыныч тормыш күрсәтмәгән.

Суд материалларыннан күренгәнчә, чираттагы эчү мәҗлесе вакытында Заһир Шәрипов шешәдәше белән ызгышып китә. Ни бүлешкәннәрен үзләре дә төгәл хәтерләми. Судта шаһит буларак катнашкан Зөлфия Гәрәева сүзләренә караганда, мәрхүм Айрат Касыймов беренче булып суга. Заһир гадәтенчә кызып китеп, өстәлдәге пычак белән шешәдәшенең күкрәгенә кадый…

Лаеш районы суды тикшерү материаллары, суд-медицина экспертизасы нәтиҗәләреннән чыгып, Заһир Иманкул улы Шәриповны Россия Федерациясе Җинаять кодексының 105 маддәсе нигезендә гаепле дип табып, каты режимлы төрмәдә тоту шарты белән 9 елга ирегеннән мәхрүм итте.

Камил СӘГЪДӘТШИН

БАШЛЫК ҮРНӘК КҮРСӘТӘ

Җирле үзидарә

Социаль челтәрләрдә Яшел Үзән районының Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы Фирая Фәйзуллинаның үзе рульгә утырып, трактор белән кар эттергәнен төшергән видеоны күргән кешеләр аңа соклануын белдерде. Фирая ханым исә тыйнак.

– Моның бернәрсәсе дә юк. Бездә бик күп хатын-кыз машина йөртә, трактор иярләүчеләр дә шактый. Мин башкалардан берни белән дә аерылып тормыйм, – ди ул.

Егерме ел бер җирлекне (ә анда биш авыл керә) җитәкләгән көчле хатын-кыз әйтә бу сүзләрне. Бу еллар эчендә төрле хәлләр күрергә, сынауларда сыналырга, җиңүләргә сөенергә насыйп булган.

– Шушы вакыт эчендә авылларыбызда халык күпкә кимеде. Үлем-китем күп. Бүген җирлектә 919 кеше яши. Яшьләрнең күпчелеге шәһәргә чыгып китә. Авылда йорт тергезүчеләр дә бар. Гомумән, бик тырыш, үҗәт, мул тормышлы халык яши бездә. Фермерлык киң үсеш алган, яшелчә, җиләк-җимеш үстерү белән күпләп шөгыльләнәләр. Пай җирләрен рәсмиләштереп, шунда үлән, ашлык үстереп сатучылар да бар, – ди ул.

Әле шушы көннәрдә авылларында зур кунаклар көтәләр икән. Биредә хәләл ял итү комплексы ачмакчы булалар. Авылда һәр төрле җиләкләр үстерү белән шөгыльләнә торган «Гектария» дип аталган фермер хуҗалыгында күк җиләккә кадәр бар. Авылдашлары кебек үк, җирлек башлыгы да балалары белән бергәләп виктория, суган үстерә.

– Ел да 2 мең төп җиләк, 10 мең төп суган утыртабыз. Бер орлыктан 780 грамм авырлыктагы суганнар үстерәбез. Узган ел, җәй коры килү сәбәпле, 480 граммлыларны гына үстерүгә ирештек. Балалар, хайван карау авыр, дип, быел бетерергә киңәш иттеләр, – ди җирлек башлыгы.

Транспорт белән дуслыгына килгәндә, аңа гаҗәпләнергә кирәкми, дип саный.

– Машина йөртә башлавыма да егерме ел чамасы инде. Бездә аның белән кеше шаккатырып булмый. Бу – гадәти күренеш, – ди ул. – Хатын-кызлар машина да, кечкенә «Кытай тракторлары»н да иярли. Җәен ирләре эштә вакытта бар эшне шуның белән эшлиләр.

Авыл советының үз тракторы юк икән. Кышын, бер оешма белән килешү төзеп, тракторны шуннан алып торалар. Ул булмаганда, авыл халкы үз тирәләрен үзләре көри, эттерә.

– Быел кардан уңдык без. Әле кичә, мәсәлән, юлларны ике трактор белән чистарттык. Урамнар тар булгач, карны куярга урын гына табып булмый. Авыллар арасын да шактый узасы. Дүртәр чакрым чистартып барырга кирәк. Килешенгән трактор кайтканчы, иртән иртүк энекәш үз тракторы белән бер урамдагы юлларны бөтенләй чистартып бетерә. Авылдашларым Айдар Ибраһимов, Илнур Шәйхетдинов, Илһам Зиннәтуллин, Рамил Назыйров, Рәис Шәрифҗанов, Радик Закировка аерым рәхмәт, – ди Фирая Фәйзуллина.

Тәҗрибәле башлык әйтүенчә, авылда рәхәт, матур итеп яшәр өчен барлык шартлар да бар. Саулык белән тырышлыгы гына булсын.

– Егерме ел авыл башлыгы булып эшләр өчен, холкың стрессларга чыдам булырга тиеш, – дип елмая ул. – Шулай ук кешеләрне ярату да – иң кирәкле сыйфатларның берсе. Тәҗрибә белән бергә кырыслыгы, усаллыгы да кирәк торгандыр инде. Эшең алга барсын өчен аннан башка да булмый. Безнең авылда су, ут буенча проблема юк. Авыл урамнарында гына 80гә якын ут баганасы бар. Бер авылда юлларны яхшыртып бетерсәк, анысы да проблема булудан туктый. Рәхәт итеп яшәгән кешегә авылыбызда бөтен мөмкинлекләр дә бар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 218

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+